КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 721

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 828 нче; 2012 ел, 7 февраль, 89 нчы; 2012 ел, 10 ноябрь, 977 нче; 2013 ел, 19 март, 191 нче; 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2014 ел, 8 июль, 465 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 846 нчы; 2019 ел, 1 февраль, 61 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.14 пунктта:

«санынннан 120%» сүзләрен «санынннан 120 процент» сүзләренә алмаштырырга;

«гомуми белем бирү оешмалары түгәрәкләрендә» сүзләреннән соң «һәм спорт резервы әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «3. Физкультура-спорт оешмалары |
|---|

| | | |
|---|---|---|
| Спорт резервы әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары | 1000 кешегә исәпләнгән физик культура һәм спорт объектларының бер тапкыр үткәрүчәнлеге 1 000 кешегә | 122 |
| | шөгыльләнүчеләр саны | муниципаль районнар, шәһәр округлары өчен – гомуми белем бирү оешмаларында шөгыльләнүчеләрнең 120 проценты (гомуми белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмалары түгәрәкләрендә шөгыльләнүчеләрне дә исәпкә алып)». |

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин